Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Өстәмә профессиональ белем бирүче
дәүләт автоном мәгариф оешмасы
«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән**

Казан
2016

**ББК 74.268.1 Тат**
**Т23**

**Проект җитәкчесе**
Р.Р. Бәдриева, МҮИ ректоры

**Төзүчеләр:**
Р.Р. Шәмсетдинова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты
Г.Н. Мөхәрләмова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
Р.Ф. Фәттахова, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
Г.В. Һадиева, МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

Татар телен һәм әдәбиятын укытуда коммуникатив технологияләр (ТР белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) – Казан: ТРМҮИ, 2016. – 53 б.

© ТРМҮИ, 2016

# ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

***Р.Р. Шәмсетдинова,***
***Р.Ф. Фәттахова***

*“Усвоение языка есть… превращение его из предметной формы в форму деятельности и затем - формирование соответствующих умений соответствующей (речевой) способности».*
*(Леонтьев А.А.)*

Тел һәм сөйләм беренче карашка бер үк төшенчәләр кебек тоелса да, алар икесе ике күренеш. Мәктәптә татар телен туган тел буларак өйрәткәндә дә, дәүләт теле буларак өйрәткәндә дә, укытучы, беренче чиратта, шушы төшенчәләрне аңлап, укыту эшчәнлегенең максатын шуннан чыгып билгеләргә тиеш. Сөйләмнең тел белән чагыштырганда киңрәк төшенчә булуына, яңа лингвистик күренешләрнең башта сөйләмдә барлыкка килеп, аннан телгә күчүенә галимнәр элек-электән игътибар иткәннәр. “Сөйләм ул – әйтеп бирү күренеше, ә тел – сүзлек хәзинәсе, гасырлар дәвамында билгеле бер тәртипкә салынган фонетик һәм грамматик төзелеш. Сөйләмне барлыкка китерүдә сөйләм ситуациясе әһәмиятле рольгә ия”, – дип билгеләп китә проф. Курбатов Х.Р. Сөйләм ситуациясе ул – үзара аралашу барышында тел һәм тормыш бәйләнешен ачык күрсәтә торган иҗтимагый, психологик һәм логик бер күренеш. Мәктәптә татар телен дәүләт теле буларак өйрәткәндә, укытучының төрле педагогик технологияләргә нигезләнеп, табигый сөйләм ситуациясе тудыра алуы бик мөһим.

Соңгы елларда педагогика фәне күп кенә фәнни төшенчәләр белән баетылды. “Педагогик технологияләр” төшенчәсе дә шундыйларга керә. Технология – грек теленнән алынган, “сәнгать” дигән мәгънәне белдерә. ФДББС да педагогик технологияләргә

төрлечә билгеләмә бирелә, дөрес, бу билгеләмәләрнең барысы да бер асылга кайтып кала: педагогик технологияләр – укыту эшчәнлеген билгеле бер эзлеклелектә оештыру һәм фаразланган нәтиҗәгә ирешү максатыннан кулланылган аерым формалар, алымнар, чаралар, методлар һәм бу процессны техник яктан җиһазландыру.

Аралашуга өйрәтү технологиясе, ягъни коммуникатив технология Е.И.Пассов, В.П.Кузовлев, В.Б.Царьков һ.б. хезмәтләренә нигезләнә. Бу технологиягә корылган дәресләрдә күнегүләр системасы аралашуга корылган. Е.И.Пассов ике төр күнегүне аерып күрсәтә: шартлы тел күнегүләре һәм тел күнегүләре. Шартлы тел күнегүләре күнекмәләр үстерү максатыннан махсус оештырыла. Бу күнегүләр бер типтагы лексик берәмлекләрнең кабатлануына нигезләнә. Тел күнегүләре аша лексика һәм грамматиканы күпләп өйрәнү мөмкинлеге тормышка ашырыла. Күнегүләр эшләү барышында хаталарны төзәтү эше дә оештырыла. Фонетик хаталарны төзәтү максатыннан һәр дәрестә фонетик күнегүләр планлаштырыла. Татар теленә генә хас булган нинди дә булса аваз алына һәм 1–2 атна дәвамында шул авазны дөрес әйтү өстендә күнегүләр эшләнелә. Ә грамматик хаталарны төзәтүгә барлык укучыларның игътибарын тарту мөһим, ләкин кагыйдәләрне анлату озакка сузылырга тиеш түгел. Коммуникатив технологиянең өстенлеге укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар булдыруда. Коммуниктив технология нигезендә укыту цикллылыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик катлаулылыгына, текстның күләменә бәйле. Методик әдәбиятта күрсәтелгәнчә, текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст алды, текст белән эшләү этабы, тексттан соңгы этап. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнәләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр – лексик күнекмәләр

һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛКФ, ГКФ). Бу дәресләрнең эчтәлеге турыдан-туры текст эчтәлеге белән бәйле. Укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнгәч, текстның үзен укуга күчәргә мөмкин. Бу дәрестә текстны уку, текст өстендә эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә. Дәрес тибы буенча әлеге дәресләр – лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре (ЛГК, ЛК, ГК), алга таба диалогик-монологик сөйләм үстерү дәресләре оештырыла. Коммуникатив метод лексик берәмлекләрне һәм аларның грамматик формаларын билгеле бер ситуацияләргә бәйләп өйрәтүне таләп итә. Чынбарлыкта кешеләр, аралашу сферасыннан чыгып, бер-берсе белән хәбәрләшәләр һәм моның өчен кирәкле тел берәмлекләреннән файдаланалар. Шуңа күрә дә икенче телне өйрәнгәндә, аралашу ситуацияләренә бәйле репликаларны истә калдыру телне гамәли үзләштерүне җиңеләйтә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыра. (Р.Б.Камаева)

В.Ф.Шаталов технологиясе укытуны камилләштерүдә схемалар һәм терәк билгеләргә таянуга нигезләнгән. Эшчәнлекне оештырганда берничә принципны исәпкә алу мөһим:

- материалны күп тапкырлар кабатлау аша үзләштерүне;
- материалны эре блокларга берләштереп өйрәнүне;
- терәк материалга таянуны;
- һәр укучыга шәхси якын килүне;
- гуманлылыкны (һәр бала талантлы!);
- мәҗбүр итмичә укытуны;
- конфликтсыз укыту, һәр баланың уңышын билгеләп, бәяләп баруны, үсеш юлларын алдан күрсәтеп эшләүне;
- укыту һәм тәрбия берлеген.

Уку процессын оештырыу һәм идарә итүнең

нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләрдән С.И. Лысенкова технологиясе. Педагог-новатор төрле интеллектуаль мөмкинлекләре булган укучылар белән өстәмә дәресләрсез, ата-аналар ярдәменнән башка эшләү методикасын

төзи. Дәрестә авыр темаларны өйрәнгәндә, башта – көчле, аннары – уртача, ахырдан исә йомшаграк укучылар эшли. Шулай итеп, белем бирү процессында, көчләреннән килгәнчә, барлык балалар да катнаша. Бу методиканың төп нигезләмәләре:

- эзлеклелек, өйрәнелә торган материалны бирүгә системалы якын килү;
- сәләтле укучының көчсезрәгенә ярдәм итүе;
- балага шәхси якын килү;
- хаталарны кисәтү;
- сыйныфта үзара ярдәмләшү мохите, уңайлы шартлар тудыру;
- уку материалының һәр укучыга көче җитәрлек итеп бирелүе.

Терәк схемалар, укытучы материалны аңлаткан вакытта, балалар күз алдында ук туа һәм схема, таблица, рәсем, карточкалар рәвешендә тәкъдим ителә. Укытучы белән алып барылган эшчәнлеккә укучы аңлатма биреп бара: («уйлыйм», «әйтәм»,«язам»). Билгеле булганча, рус сыйныфларында укучыларның әзерлек дәрәҗәләре төрлечә була. Шул сәбәпле, татар теле дәресләрендә С.Н.Лысенкова технологиясен файдалану (бигрәк тә башлангыч сыйныфларда) өйрәнелә торган телдә сөйләм эшчәнлегенең белем һәм күнекмәләрен үзләштерүне яңа дәрәҗәгә күтәрүне тәэмин итә. Материалның схемаларга салынып бирелүе күрү хәтере яхшырак булган укучылар өчен бигрәк тә уңайлы санала, шулай ук башкаларга да билгеле бер теманы, тел күренешен схема рәвешендә системалы истә калдырырга ярдәм итә.

Мәктәптә татар теленә һәм әдәбиятына өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

- укучының танып белү активлыгын арттыру;
- сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

- укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

- укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, уку теләген тагын да үстерү.

Белем бирүдә яңа технологияләр куллана башлау сөйләм эшчәнлеген оештырудагы ясалмалыктан котылырга, укучыларның эшчәнлек төрләрен алмаштырып торырга, сөйләм ситуациясен барлыкка китерергә мөмкинлек бирәчәк. Бу юнәлештә аеруча коммуникатив технологияләрне куллану уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итәчәк.

Коммуникатив метод телләрне өйрәнүдә иң эффектив метод буларак санала, бигрәк тә ул Европа илләрендә, АКШта бик популяр. Россиядә бу технология чит телләрне өйрәтү өлкәсендә барлыкка килгән, Е.И. Пассов, И.А.Зимняя, А.А.Леонтьев, Г.А.Китайгородская исемнәре белән бәйле.

Коммуникатив технология, исеменнән аңлашылганча, аралашу мөмкинлеген тудыруга юнәлтелгән. Бу методның максаты – өйрәнә торган телдә аралашкан вакытта киеренкелек, курку хисен бетерү, аралашу өчен максималь уңай халәт тудыру, ягъни сөйләм ситуациясе барлыкка китерү. Кеше 1000-1500 сүз запасы белән теләсә кайсы телдә аралаша ала. Дөрес, укучыларны телгә өйрәткәндә, коммуникатив технологиягә, укучыларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып, традицион укыту элементларын да кертеп укыту максатка ярашлы.

Телгә өйрәтү 4 бурычны үтәүне күздә тота: укучыны бу телдә 1) сөйләмне ишетеп аңларга, 2) сөйләшергә 3) укырга, 4) язарга өйрәтү. Татар телен коммуникатив технология нигезендә өйрәткәндә дә бу бурычлар тормышка ашырыла. Дәресләрдә аралашу (ситуатив биремнәр, диалоглар төзү, дискуссия), текст белән эшләү, күнегүләре үткәрелә. Шул ук вакытта аудио-, видео- һәм интерактив ресурсларны куллану бик әһәмиятле.

Рус төркемнәрендә татар телен укытуда коммуникатив технологияне куллану укучыларда түбәндәге коммуникатив компетенцияләрне формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк:

- татар телендә төрле максатларда һәм ситуацияләрдә аралаша белү күнекмәләре барлыкка килү;
- аралашу өчен продуктив лексик минимумны үзләштерү;
- фонетика, лексикология, грамматикага караган материалны төрле аралашу ситуацияләрендә дөрес куллана белү;
- диалогик сөйләм күнекмәләре барлыкка килү;
- аерым темалар буенча монологик сөйләм күнекмәләре формалашу;
- татар телендә текстларны укып аңлау, укыган буенча фикер әйтә белү.

Татар теленә өйрәтү, нинди генә технология кулланылса да, татар мәдәниятенә, тарихына хөрмәтле караш формалаштыру; табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга толерантлык формалаштыру белән берлектә барырга тиеш.

Рус мәктәпләрендә коммуникатив юнәлештә татар телен укыту процессы түбәндәге ***принципларны*** истә тотып тормышка ашырыла:

1. *Актив сөйләм принцибы, ягъни телне актив аралашу аркылы өйрәтү.* Бу принцип дәреснең гамәли характерын билгели. Телне грамматикадан аралашуга таба түгел, ә аралашудан грамматик нормаларны камилләштерүгә таба өйрәнү максатка ярашлы. Димәк, дәрестә актив аралашуга корылган күнегүләр үткәрелә, бу күнегүләр аша салмак, сиздермичә, ләкин максатчан, “дозалап” телнең грамматик нормаларын үзләштерү, лексикасын өйрәнү һәм актив сөйләмдә грамоталы итеп куллану тормышка ашырыла. Сөйләмдә кулланылмый торган фразалар дәрестә өйрәнелми.

Атаклы психологлар А.Н. Леонтьев, П.Я. Гальперин фикеренчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик кызыксыз, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә башта

балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана.

2. *Функциональлек принцибы.* Сөйләм эшчәнлегендә өч юнәлеш тыгыз бәйләнештә: лексик, грамматик, фонетик. Аралашуга корылган эшлекле биремнәрдә төрле тел берәмлекләре үзләштерелә: укучы сорау бирә, фикерне раслый, инкарь итә, шикләнә, риза була, әңгәмәдәшен ниндидер эшкә чакыра һ.б. Һәрбер очракта билгеле бер грамматик форманы үзләштерү һәм ныгыту тормышка ашырыла. Грамматик материал авыр, озын кагыйдәләр биреп ятлату формасында түгел, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителә. Аларны үзләштерү сөйләм ситуацияләре нигезендә оештырыла. Лексик-грамматик формалар җиңелрәк формадан башлап, әкренләп катлауландырыла.

3. *Ситуативлык принцибы* – укыту материалын сайлаганда һәм укыту процессын оештырганда, укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм кызыксынуларын искә алып, проблемалы ситуацияләрне коммуникатив хәл итүгә максималь игътибар бирелә. Укучылар, төрле рольләргә кереп, ситуацияле уеннарда катнашалар. Ситуатив биремнәрне дөрес формалаштыруга аеруча игътибарлы булырга кирәк, мәсәлән, “Балалар мәйданчыгында”, “Касса янында”, “Аптекада” дип кенә ситуатицияне атап үтү генә ситуация барлыкка китерми, аралашу ихтыяҗы барлыкка килми, сөйләм күнекмәләре формалашмый. Бары реаль ситуация эчендә реаль рольләргә бүленеп кеә укучыларда аралашу ихтыяҗы барлыкка китереп була.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шунда ук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә.

4. *Яңалык принцибы.* Бу дәреснең төрле компонентларында чагылыш таба: сөйләм ситуацияләрнең яңалыгы, ягъни аралашу предметының/темасының, сөйләшү

проблемасының, партнерларның, сөйләшү шартларының алмашынуы/дәрес саен үзгәреп торуы, дәресне төрлечә оештыру (төрен, формасын), укыту алымнарын алмаштыру.

5. Һәр баланың сөйләм күнекмәләре төрлечә формалаша. Моңа төрле факторлар йогынты ясый: психофизиологик, социаль, укучыларның яшәү тирәлеге, кызыксыну сфералары, эшчәнлек төрләре һ.б. Болар барысы да шулай ук коммуникатив сәләткә йогынты ясый. Шуңа күрә *уку процессын индивидуальләштерү принцибы* – укыту процессын укучыларның теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыруны күздә тота.

Димәк, коммуникатив компетенцияләрне уңышлы үстерү өчен укытучы һәр укучыга шәхси якын килеп кенә ирешә ала:

- укучының индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тоту;
- укучының уңай сыйфатларын алга чыгару;
- укучының шәхси уңышларын ныгыту, күрсәтү.

Белем бирү өлкәсендә укучыларның коммуникатив үсешен тәэмин итү балаларның психологиясен һәм шәхесе үсү законнарын һәм механизмнарын белеп эш иткәндә генә нәтиҗәле була. Телгә өйрәтү дәресләрендә төрле кызыклы сөйләм ситуацияләрен оештыру, шуларга нигезләнеп, укучыларның аралашу осталыгын үстерүгә игътибарны арттыру, укучыларга төрле социаль рольләр башкару, кирәкле репликаларны дөрес куллану өчен сөйләм эшчәнлеген оештыру мөһим. Сөйләм ситуациясен оештырганда, коммуникатив биремнәрдән, сюжетлы рәсемнәрдән, мультфильмнар, фильмнардан алынган өзекләрдән, презентацияләрдән, коммуникатив уеннардан файдалану яхшы нәтиҗәләр бирә. Бу эш төрләре, билгеле инде, балаларның кызыксыну даирәләреннән, яшь үзенчәлекләреннән, сәләтләреннән чыгып сайланырга тиеш. Аралашуга корылган дәресләрдә коммуникатив уеннар оештыру аеруча отышлы. Уйнаганда, балалар үзләренә якын булган сөйләм ситуацияләрен җанландыра,

проблемалы ситуацияләр барлыкка китерә һәм шуларны чишүгә ирешә алалар.Коммуникатив уеннарның тәрбияви әһәмияте дә зур: укучыларда игътибарлылык, ярдәмчеллек, үз-үзләренә ышанучанлык, үз уңышларына шатлану хисләре тәрбияләнә. Укытучылар тарафыннан уңышлы рәвештә кулланыла торган уеннардан, мисал өчен, түбәндәгеләрне атап китәргә мөмкин.

Интервью алу.

Бу уенны оештыруның нигезе булып, уңышлы төзелгән сораулар тора, аларны таблица итеп тә, схема итеп тә төзергә мөмкин. Беренче чиратта, интервью алынучы кеше турындагы барлык мәгълүматны ачыкларга кирәк. Сораулар “әйе”, “юк” кебек җаваплар бирерлек итеп кенә куелмаска тиеш. Әгәр әңгәмәдәш булган кеше сорауны аңламаса, сорауга ачыклык кертелә, ә соңгы сорау йомгаклау характерындагы булырга тиеш. Сораштыруны түбәндәгечә оештырырга мөмкин: 4-5 укучы такта янына чыга, алар сорауга җавапларын тактага төшергән рәсемнәре аша бирәләр (шулай ук тәкъдим ителгән фоторәсемнәрдән дә сайлап алуны оештырыга мөмкин). Аннан соң төркемнәргә берләшеп, нинди ситуациядә үзләрен ничек тотырлар иде, дигән темага әңгәмә коралар. Түбәндә әлеге төр сөйләм эшчәнлегенең үрнәк схемасы китерелә.

| схемалар | Үзара сөйләшүгә мисаллар |
|---|---|
| - сорау<br>- җавап | - Сез Болгар, Зөя шәһәрләрендә булдыгызмы?<br>- Без әле Казан белән генә таныштык. |
| - сорау<br>- каршы сорау<br>- җавап | - Дустың татарча сөйләшәме?<br>- Кайсы дустым?<br>- Кичә безнең белән очрашуда булган. |
| - чакыру<br>- риза булмау | - Әйдәгез, иртәгә Болгарга барабыз.<br>- Гафу итегез, бара алмыйбыз. Иртәгә студентлар белән очрашу билгеләнгән. |
| - Чакыру | - Әйдә, Идел буйлап 1 көнлек сәяхәткә чыгабыз. |

| | |
|---|---|
| - риза булмау<br><br>- үгетләү<br><br>- ризалык белдерү | - Юк, мин бара алмыйм. Өйдә эшләрем күп.<br>- Иртәгә көн бик матур була. Рәхәтләнеп ял итеп кайтырбыз, Идел буйларындагы матурлыкны күрербез.<br>- Яхшы, өйдәге эшләрне бүген эшләрмен. |
| - хәбәр итү<br><br>- раслау | - Быел безнең мәктәпнең 100 еллыгы булачак икән.<br>- Шулай икән шул. Мин дә белдерү ишеттем. |
| - сорау (үтенү)<br><br>- ризалык белдерү | - Зинһар өчен, миңа даруханәдән дару алып кайтып бирче?<br>- Борчылма, хәзер алып кайтам. |
| - Чакыру<br><br>- рәхмәт белдерү, риза булу | - Мин спектакльгә билетлар алдым, сезне театрга чакырырга телим.<br>- Рәхмәт, бик теләп барам. |
| - Тәкъдим<br><br>- ризалык белдерү, каршы тәкъдим | - Әйдәгез әле, бергәләп М.Җәлил музеена барып кайтыйк.<br>- Яхшы, минем дә күптән барасым килә. Аннан соң бергәләп төшке аш ашарбыз. |
| - сәламләү<br>- каршы сәламләү<br>- сорау<br>-<br>- җавап | - Хәерле көн, Наилә Солтановна!<br>- Хәерле көн, Марат!<br>- Наилә Солтановна, очрашуга килә аласызмы?<br>- Килергә тырышырмын. |

Бүгенге көндә рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен тәкъдим ителгән УМКлар, нигездә, коммуникатив технология таләпләренә нигезләнеп төзелгән. Укытучылар коммуникатив технологияләрнең нигезләрен яхшы үзләштереп, уңышлы гына дәрес үрнәкләре дә күрсәтәләр. Методик кулланмада аерым укытучыларның эш тәҗрибәләрен чагылдырган язмалары, дәрес үрнәкләре тәкъдим ителә.

## «ТАУ АСТЫННАН ЧИШМӘ ТИПКӘН...»
## («Чишмә» темасына бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе. V сыйныф. Рус төркеме)

***Илмира Әбсәләмова,***
*ТР Казан шәһәре 39 нчы мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Гөлназ Әхмәтова,***
*ТР Казан шәһәре 39 нчы мәктәпнең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Дәрес төре: катнаш (әдәби уку, татар теле)

Дәрес тибы: яңа белем бирү

Технология: тәнкыйди фикер йөртү, Библерның «Мәдәни диалог» технологияләре.

Максат

*Белем бирү:* укучыларны икетеллек шартларында фикерләргә өйрәтү, аралашу күнекмәләре формалаштыру.

*Үсеш:* нәтиҗә ясарга өйрәнү, чагыштыра һәм гомумиләштерә белүне үстерү.

*Тәрбияви*: күпмилләтле республикада яшәвебезне искә алып, укучыларда әдәби әсәрләр (Гамил Афзал һәм Иван Бунинның поэтик әсәрләре) нигезендә туган телгә, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү.

Бурычлар

1. «Бер һәм күп мәгънәле сүзләр» төшенчәсен актуальләштерү.
2. *Кластер* һәм *синквейн* нигезендә сүзләрнең мәгънәви-охшаш (ассоциатив) кырын таба белергә һәм текст төзергә өйрәтү.

Дидактик принциплар: проблемалылык, аңлаешлылык, системалылык.

Дәрес барышы

I. Оештыру өлеше

Уңай психологик халәт тудыру. Исәнләшү. Укучыларның бер-берсе белән сәламләшүе.

– Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн!

– Исәнмесез!

– Укучылар, җилкәдәш партнерыгызга һәм каршы утыручы партнерыгызга карагыз әле. Җилкәдәш партнерыгызга «биш»не бирегез, ә каршы утыручы партнерыгызны матур елмаеп сәламләгез.

II. Актуальләштерү

*(Укытучының кулында төрле тойгылар язылган кәрҗин.)*

– Кәрҗиннән үзегезгә охшаган төсне сайлап алыгыз һәм анда язылган тойгыларны укыгыз. *(Шатлык, аптырау, мәхәббәт, бәхет һ.б.)*

III. Яңа материалны аңлату

– Сезнең күңелләрегездә бары тик яхшы тойгылар гынадыр. Минем күңелем дә ак кәгазь бите кебек чиста һәм анда якты хисләр. Кулымдагы кәгазьдә кечкенә генә шигырь язылган. Күзләремне йомсам – минем күз алдыма әлеге шигырь юлларындагы сурәт килеп баса. Мин сезнең дә әлеге матурлыкны күрүегезне, тоюыгызны телим. Үзегезне рәссам итеп күз алдына китерегез. Әлеге юлларны укыганда нәрсә ясар идегез? Шуларны языгыз.

В глуши лесной, в глуши зеленой,
Всегда тенистой и сырой,
В крутом овраге под горой
Бьет из камней родник студеный.
Кипит, играет и спешит,
Крутясь хрустальными клубами,
И под ветвистыми дубами
Стеклом расплавленным бежит.
А небеса и лес нагорный
Глядят, задумавшись в тиши,
Как в светлой влаге голыши

Дрожат мозаикой узорной. *(Иван Бунин, «Родник»)*

*(Чишмәләрне төрлечә чагылдырган видеоролик күрсәтелә.)*

IV. Ныгыту

– Укучылар, экранга карагыз һәм *чишмә* сүзенә охшаш (ассоциатив) рәт языгыз.

Стё зе класс

1) 30 секунда эчендә укучылар «Чишмә» сүзенә охшаш сүзләр язалар;

2) шушы сүзләр астына сызык сызалар;

3) сыйныф буенча йөриләр; пар табып, яңа сүзләр язалар; тәңгәл килгән сүзләр янына «+» тамгасы куялар;

4) 2 пар табып язгач, утыралар.

– Бик күп сүзләр тапкансыз, укучылар, булдыргансыз. Һәр команданың үз исемлеге барлыкка килергә тиеш.

Ол Райт Раунд Робин

1) 2 мин. вакыт бирелә;

2) 3 нче номердан башлап, укучылар сүзләрен укыйлар, мөһим сүзләрне бер биткә язып, исемлек төзиләр. 4 укучы өчен дә бер исемлек төзелә.

– Вай Фай! (3–4 баланың җаваплары тыңлана: *авыл, су, җир, үлән*).

– Укучылар Ә хәзер алган белемнәребезне тикшерик.

Һәр төркем «Чишмә» темасына караган сүзләрне язасыз һәм бер-берегез белән фикер уртаклашасыз.

Джот Тотс

1) «Чишмә» темасына караган берәр сүз уйлыйлар һәм стикерга язалар;

2) кычкырып, команда эчендә әйтәләр, сүзләр кабатланырга тиеш түгел;

3) һәр укучы 4 сүз әйтеп, стикерны өстәл уртасына куя.

Тик Тэк Тоу

1) стикерга язылган сүзләрне алалар, кушып буташтыралар;

2) 9 стикер калдыралар, 3х3 формасында төзиләр һәм шакмакларга номерлар язып куялар

| | | |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 4 | 5 | 6 |
| 7 | 8 | 9 |

Командадагы һәр укучы, бер сызыктагы (диагональ, горизонталь, яки вертикаль) 3 сүзне алып, җөмлә төзи.

Раунд Робин

– Ә хәзер һәр укучы җөмләсен укып чыга. 2 нче номердан башлыйбыз.

Физкультминут

Текст белән эш

*Укучылар алдында текст – «Чишмә»*

– Текст белән танышыгыз һәм һәр җөмләне шартлы тамга белән билгеләгез.

*Җөмлә аңлашылса, балалар «+» куялар, аңлашылмаса, «–» куялар, сорау тудырса «?» куялар.*

Чишмә

Авылда үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. «...»

Аны туган җиренә тәмле сулы, моңлы җырлы чишмәләр тарта. «...»

Безнең ата-бабаларыбыз авылларны чишмә буена салганнар. «...» Аларны карап, чистартып торганнар. «...»

Һәр авылның үз чишмәсе бар. «...» Кешеләр чишмәләргә матур-матур исемнәр биргәннәр. «...» Җидегән чишмә, Изгеләр чишмәсе, Гашыйклар чишмәсе, Тау чишмәсе... «...» Саф чишмә суы сәламәтлеккә дә файдалы. «...»

Яшел яфраклар шаулап торган, чишмәләр чылтырап аккан урында яшәү нинди бәхет!

*(Укытучы текстның тәрҗемәсен тәкъдим итә.)*

Родник

Человек, который вырос в деревне и живет далеко, всегда вспоминает родной край. Его к родному краю притягивают вкусная вода и родники. Наши бабушки и дедушки строили деревни около родников. Родники чистили. За ними ухаживали.

У каждой деревни есть свой родник. Люди давали родникам разные названия: Святой родник, родник Влюбленных, Горный родник и т.д. Свежая чистая вода – это жизнь.

Какое счастье жить там, где шумить листва и течет родник!

Мөстәкыйль *(практик, контроль)* эш

«Блум Ромашкасы»

– Текст белән эшлибез. Сорауларга җавап бирәбез.

*«Ромашка»* сораулары

| | | |
|---|---|---|
| Күчермә | Гади | Кем? Кайчан? Кайда? Ничек? |
| Аңлау | Аныклаучы | Мин дөрес аңладыммы? |
| Куллану | Гамәли | Ничек кулланып була? |
| Анализ | Аңлатучы | Ни өчен? |
| Синтез | Ижади | Әгәр ... нәрсә була? |
| Бәяләү | Бәяләү | Сезнең мөнәсәбәтегез? |

– Нәрсә ул чишмә? Әлеге сүзнең тамырын табыгыз, бер тамырдан торган сүзләрне билгеләгез. Әлеге сүзнең кыйммәтен аңлатырга тырышыгыз.

– Чишмәләрне ничек саклап була, сез ничек уйлыйсыз?

– Ни өчен кешеләр чишмә янынннан урын сайлаганнар?

– Ни өчен чишмәләргә матур исемнәр биргәннәр?

*(Укучылар сорауларга җавап бирәләр.)*

Тайм Пэа Шэа

Һәр укучыга 20 с вакыт бирелә. Җаваплар «А» партнерлардан башлыйбыз.

– Хәзер сезнең игътибарыгызга татар әдибе Гамил Афзалның «Чишмә башы» дигән шигырен тәкъдим итәм. (Әдип турында берике җөмлә белән мәгълүмат бирелә.)

«Чишмә башы»

Тау астыннан чишмә типкән,
Салкын гына суы саф көмеш
Челтер-челтер итеп агып киткән,
Дөнья буйлап киткән саф килеш.
Анда килеп намаз укыганнар
Мосафирлар дога кылганнар
Чишмә башы – изге урын диеп,
Тәсбих әйтеп торган урманнар.

– Сезгә нинди сүзләр таныш түгел, бергәләп мәгънәләрен ачыклыйк. Джот Тотс структурасы ярдәмендә чишмә сүзенә охшаш (ассоцион) рәт төзегез. Ике телдәге шигырь арасында нинди аерма бар? *(Чишмә – чиста су һәм чишмә – изге саф урын, рухи яктан ачыла.)*

– Ә хәзер без уй-фикерләребезне тулырак ачыклыйбыз. Һәм без үзебезнең иҗади остаханәбездә могжиза тудырабыз.

Рефлексия.

– Укучылар, без сезнең белән И.Бунин һәм Г.Афзал шигырьләрен тыңладык, ә хәзер синквейн төзибез, схеманы тутырабыз.

| |
|---|
| Исем (тема) |
| Сыйфат, сыйфат. |
| Фигыль, фигыль, фигыль. |
| Тема буенча дүрт сүздән торган фраза. |
| Исем (теманың синонимы, теманы ачыклаучы сүз) |

Cималтиниус Раунд Тейбл

Укучылар божра буенча таблицаны тутыралар:

- ♦ исем сүз төркеме (тема);

- 2 сыйфат
- 3 фигыль;
- тема буенча дүрт сүздән торган фраза;
- исем (теманың синонимы, теманы ачыклаучы сүз).

*Мәсәлән,*

- Чишмә.
- Чиста, саф.
- Чыңлый, ага, яши.
- Чишмә – чиста су чыганагы.

*Укытучы 4 укучыдан сорый.*

Йомгаклау.

– «Чишмә» сүзе күп мәгънәдә килә. Сезнең иҗади эшләрегез шуны раслады.

*Татарстан төбәгендәге чишмәләрдән видеосюжет күрсәтелә.*

– Тормышка ышаныгыз, тормышны яратыгыз, тормыш ул – яшәү чыганагы, саф сулы чишмә кебек һәрчак рухны баетып тора.

Өйгә эш

«Чишмә – яшәү чыганагы» дигән темага 5–6 җөмләдән торган иҗади эш.

Дәреснең технологик картасы

| | |
|---|---|
| Дәреснең максаты | *Дидактик:* шигырьгә анализ ясау күнекмәләре формалаштыру.<br>*Аңны үстерү:* шигырьләрне чагыштырып өйрәнү аша табигать белән танышу,фикерләрне бер-берсенә җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, алган белемнәрне камилләштерү<br>*Тәрбияви:* күпмилләтле республикада яшәвебезне искә алып, укучыларда әдәби әсәрләр нигезендә туган телгә, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү |
| Дәреснең бурычлары | 1. «Бер һәм күп мәгънәле сүзләр» төшенчәсен актуальләштерү.<br>2. Кластер нигезендә сүзләрнең мәгънәви-охшаш (ассоциатив) кырын таба белергә һәм текст төзергә өйрәтү |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | *Шәхескә кагылышлы:* Чишмә – рухи һәм физик яктан саф, чиста су, яшәү, тормыш.<br>*Метапредмет (регулятив, танып-белү, коммуникатив):* чишмәләрне сакларга, яшәешне дәвам итә торган изге су буларак чистартып торырга кирәклеген аңлау<br>*Предмет*: *чишмә* сүзенә охшаш рәт төзү, тамырдаш сүзләрне билгеләү. |
| Предметара бәйләнешләр | Рус теле |

| | |
|---|---|
| Эшне оештыру төрләре | Парлап, төркем белән |
| Төп төшенчәләр | Исем, сыйфат, фигыль сүз төркемнәре; чишмә |
| Педагогик технологияләр: | Шәхескә юнәлдерелгән |
| Дәрес тибы | Катнаш (татар теле, әдәби уку) |
| Дәрес төре | Бәйләнешле сөйләм үстерү |
| Материал | Дәреслек (Татар теле. V сыйныф. Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. / Р.Х.Ягъфәрова, К.С.Фәтхуллова. – Казан: Тат. китап нәшр., 2014), И.Бунин, Г.Афзал шигырьләре; текст, «Блум ромашкасы» |

| Дәрес этаплары дәреснең технологиясе һәм төреннән чыгып билгеләнә | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Белем бирү һәм үстерү биремнәре (дәреслек, предмет материалы) | УУД *Рухи-әхлакый үсеш (РӘҮ),* танып-белү (Тб), регулатив (Р), Коммуникатив (К) | Диагностик, этәргеч сораулар, тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|
| Ориентлашу, мотивлашу. *Максат:* эшкә | Укучылар белән исәнләшү. | Бер-берсен сәламлиләр. Хәерле көн | | *РӘҮ:* тормышта үз урыныңны табарга әзерлек; | Дәрескә һәр укучыың яхшы кәеф |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| кызыксыну ту-дыру | Дәрескә әзерлекне тикшерү | телиләр | | *Тб:* өйрәнелә торган объектка хас төп үзенчәлекләрне аерып күрсәтә белү; *Р:* проблеманы аерып ала белү; *К:* тыңлый, ишетә белү | белән килүе ачыклана |
| Акту-альләштерү. *Максат:* яңа материалны үзләштерүгә әзерлек булдыру | Укучыларга кәрҗиннән үзләренә охшаган төсне сайлап алырга һәм анда язылган тойгыларны укырга тәкъдим итеәлә | Укучыларның җаваплары тыңланыла. Алар үзләренең хис-тойгыларын белдерәләр | Төрле тойгылар язылган карточкалар белән эш | *РӘү:* кешегә хас булган хис-тойгыларны аерып күрсәтә белү; *Тб:* дәрестә алына торган мәгълүматка бәйле рәвештә хис-тойгыларны аерып күрсәтә белү; *Р:* чишелергә ти- | Сез нинди хис-тойгылар кичерәсез? Алар нәрсә белән бәйле? Кәефегезгә нәрсәләр тәэсир итә? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ешле проблеманы аерып ала белү;<br>*К:* үз-үзеңне тотуның әхлакый асылын аера белү | |
| Яңа материалны аңлату.<br>*Максат:* укучыларны икетеллелек шартларында фикерләргә өйрәтү, аралашу күнекмәләре формалаштыру | И.Бунинның «Родник» шигырен өйрәнү ярдәмендә яңа белем бирү | Укучыларның шигырь белән танышканнан соң алган хисләрен язу. Чишмә сүзенә охшаш (ассоциатив) рәт төзү. Стё зе класс. Ол Райт Раунд Робин | И.Бунинның «Родник» шигыре, чишмәләрне чагылдырган видеоролик | *РӘҮ:* шәхесара мөнәсәбәтләрдә һәм социаль рольләрдә ориентлаша белү;<br>*Тб:* өйрәнү объектларын чагыштыру, классификацияләү өчен нигез сайлый белү;<br>*Р:* проблеманың иң эффектив чишелеш юлын аерып ала белү; | Рәссам булсагыз, шигырьдән алган хисләрегезне ничек сурәтләр идегез? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *К:* үз фикереңне туган телнең грамматик нормаларына туры китереп әйтә белү; | |
| Материалны ныгыту.<br>*Максат:* алган белемнәрне төрле алымнар ярдәмендә ныгыту | Укучыларга белемнәрне ныгыту биремнәрен аңлату. Алдагы дәресләрдә алган белемнәргә нигезләп, яңа белемнәр үзләштерүне оештыру | Укучылар, алдагы белемнәрен кулланып, биремнәр үтиләр: акыл штурмы (Джот Тотс һәм Тик Тэк Тоу). *Инсерт* ярдәмендә текстны шартлы тамгалар белән билгелиләр, сүзләрне кул- | И.Бунинның «Родник» шигыре, «Чишмә» тексты | *РӘҮ:* укучының әйләнә-тирәне күрә һәм аңлый белү мөмкинлеге;<br>*Тб:* планлаштыруны, тикшерүне оештыру;<br>*Р:* проблеманы мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә өйрәнү;<br>*К:* алган мәгълүмат хакында төрле | Шигырьдә кайсы сүз терәк сүз булып килә? Әлеге сүз нәрсәне аңлата? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ланып җөмләләр төзү. Раунд Робин | | ысуллар кулланып хәбәр итә белү | |
| Физкультминут. *Максат:* фикер эшчәнлеген арттыру, физик яктан ял итү | Укучыларга хәрәкәтләр күрсәтү | Укытучы күрсәткән хәрәкәтләрне кабатлау | Музыка | *РӘу:* әйләнәтирәдәгеләрне ихтирам итә белү;<br>*Тб:* өйрәнелә торган объектка хас формаларны сайлый белү;<br>*Р:* нинди юнәлештә камилләшү мөмкинлеген күрсәтү;<br>*К:* проблемаларны бергә хәл итә белү | |
| Мөстәкыйль *(практик, кон-* | Яңа тема буенча алган | «Блум ромашка»сы | «Блум ромашка»сы | *РӘу:* үзеңнең эшгамәлләреңә мак- | Нәрсә ул чишмә? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| *троль)* эш<br>*Максат:* алган белемнәрне тикшерү | белемнәргә тикшерү оештыру | ярдәмендә сорауларга җавап бирү, грамматик биремнәр үтәү, текст өстендә эш. Тайм Пэа Шэа | | сатчан юнәлеш сайлый белү;<br>*Тб:* белем алу барышында үз-үзеңә бәя бирүне оештыра белү;<br>*Р:* аерып алынган проблеманы мөстәкыйль хәл итә алу;<br>*К:* үз фикереңне дәлилле итеп коллективта аңлата белү. | Сүзнең тамыры нинди? Тамырдаш сүзләр нинди була? |
| Нәтиҗәләрне бәяләү.<br>*Максат:* белем дәрәҗәсен бәяләү | Укучыларның алган белемнәренә нәтиҗә ясый | Үз белемнәренә бәя бирәләр | Таныш булмаган сүзләрне ачыклау һәм ике телдәге шигырьне | *РӘү:* үзеңнең эшгамәлләреңә максатчан һәм мәгънәви юнәлеш сайлый белү;<br>*Тб:* максат куя | Ни өчен чишмә сүзе күп мәгънәдә кулланыла? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | чагыштыргач<br>туган фи-<br>керләр ту-<br>рында әңгәмә<br>үткәрү | белү, куйган мак-<br>сатны бәяли белү;<br>*Р:* үз эшеңә адек-<br>ват бәя бирә<br>белү;<br>*К:* төркем белән<br>эшләү күнек-<br>мәләре булдыру | |
| Рефлексия.<br>*Максат*:<br>тәҗрибәне арт-<br>тыру | Укучыларны<br>беренчел фи-<br>керләргә<br>кайтара | Укучы яңа ал-<br>ган белем-<br>нәрен алдагы<br>белемнәре<br>белән чагы-<br>штыра. *Кла-<br>стер, синквейн*<br>төзү. Симал-<br>тиниус Раунд<br>Тейбл | Г.Афзалның<br>«Чишмә» ши-<br>гыре,<br>И.Бунин<br>«Родник» ши-<br>гыре | *РӘү:* шәхесара<br>мөнәсәбәтләрдә<br>аралаша белү;<br>*Тб:* алган белем-<br>нәрне чагыштыра<br>белү, фикер үсте-<br>релешенең,<br>дәлилләүнең ло-<br>гик чылбырын<br>төзү;<br>*Р:* үз эшенә бәя<br>бирә, рефлексия | *Чишмә* сүзе<br>нинди<br>мәгънәләрне<br>аңлата? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ясый;<br>*К:* яшьтәшләре белән уртак гамәлләр оешты-ра | |
| Дәресне йом-гаклау.<br>*Максат:* дәрестә узган-нарны анализ-лау | *Чишмә* сүзенең күп мәгънәне аңлатуын һәм, яшәү чыганыгы буларак, тормыштагы әһәмиятенә төшендерү | Ижди эшләре белән *чишмә* сүзенең күп мәгънәле бу-луын раслау | Татарстанда-гы чишмәләр турындагы видеоролик | Үз фикереңне тулысынча төгәл итеп әйтеп бирә белү | Чишмәләрн е ни өчен сакларга кирәк? |
| Өй эше бирү (тәкъдимнәр) | Өй эшен бирү, аңлату | Өй эшен көндәлек-ләренә язу | | | |

# КАЗАН – РЕСПУБЛИКАБЫЗ БАШКАЛАСЫ
## (VI сыйныфның рус төркемендә татар теле дәресе)

***Лариса Исмәгыйлова,***
*ТР Казан шәһәре 39 нчы мәктәпнең I нче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәрес тибы**: теманы йомгаклау.

**Максатлар:**

1. **Белем бирү**: Казан турында алган белемнәрне тормышның төрле ситуацияләрендә кулланырга өйрәтү. Казан шәһәре белән бәйле лексик берәмлекләрне кулланып коммуникатив компетентлыклары камилләшү өчен җирлек тудыру

2. **Аңны үстерү**: Дәрестә Казан темасына кагылышлы коммуникатив компетентлылык формалаштыру. Образлы фикер һәм фәнни (гомумиләштерү, чагыштыру) эшчәнлеге үсеше өчен җирлек тудыру

3. **Тәрбияви**: Казанның тарихи – мәдәни урыннары хакында белү һәм татар телендә дә аңлатып бирерлек булу ихтыяҗы уяту

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

- Шәхескә кагылышлы-башкалабыз Казан белән горурлык хисе тәрбияләү. Үзең яшәгән җиргә, аның тарихи-мәдәни мирасына карата ихтирамлы, киләчәге өчен җаваплы булу.
- Метапредмет – Казан шәһәре турында булган белемнәребезне кулланышка кертү, гомумиләштереп нәтиҗә ясый белү, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.
- Предмет-шәһәребез Казан шәһәре турында булган белемнәребез белән таныштыру, өстәмә материаллар аша белемебезне баету, Казанның дөньякүләм әһәмиятле шәһәр булуын ассызыклау, әлеге тема буенча үзләштерелгән лексиканы

кулланып сүзлек запасын арттыру, сораулар ярдәмендә диалогик һәм язма сөйләмгә чыгу күнекмәләрен устерү.

**Ресурслар**: дәреслек Р.З. Хәйдәрова, З.Р. Нәҗипова “Татар теле” 6 нчы сыйныф, төрле эчтәлектәге карточкалар.

**Җиһазлау**: экран, презентация,блокнотлар,чемодан.

**Дәрес барышы**

1. **Мотивлаштыру-ориентлаштыру** *(психологик уңай халәт тудыру)*

1. Дәресне оештыру.

*“Сәлам” җыры яңгырый.*

– Сәлам, укучылар. *(Исәнмесез)*

– Дәресебезне матур жыр белән башладык. Шулай күтәренке рухта, кызыклы үтсен дәресебез.

2. Белемнәрне актуальләштерү.

– Минем кулымда нәрсә? (*Чемодан) Слайд (чемодан)*

– Әйе, мин бүген чемодан белән килдем. Чемодан ни өчен кирәк?

– *(Юлга чыгу өчен, сәяхәт итү өчен, киемнәр салу өчен...)*

– Бу серле чемодан. Аның эчендә төрле, кызыклы сынаулар бар.

– Әйе, балалар. Юлга чыкканда чемодан гына түгел, дуслар да, юлдашлар да кирәк. Шул вакытта гына безнең юлыбыз күңелле, уңышлы булыр.

– Менә мин дә бүген зур юлга чыктым һәм сезне дә үзем белән чакырам. *Слайд (континентлар)*

– Ә нинди транспорт белән юлга чыгарга була*? Слайд (транспортлар: поезд, самолет, автобус, машина, кораб)*

– Ә бу транспортка утырыр өчен нәрсә кирәк*?* ***(****Билет)*

– Мин сезгә хәзер серле чемоданнан юл билетлары тапшырам. Бу билет, серле билет. Игътибар белән карагыз әле, сез кайсы илдән килдегез?

– Мин Татарстаннан. Ә син кайдан? *Слайд (чемоданнан сораулар чыга: кемнән, нәрсәдән, кайдан...)*

*(Америкадан, Кытайдан, Россиядән, Англиядән, Франциядән, Италиядән, Германиядән)*

– Без барыбыз да кунаклар. Әйдәгез юлга чыгыйк. *Слайд (самолет оча)*

– Кунаклар, без аэропортта, Татарстанда. Ә сез беләсезме, 2018 елда Татарстан республикасына 100 ел була. *Слайд (аэропорт күренеше)*

*Укытучы "Мин яратам сине, Татарстан!" шигырен сөйли (өзек)*

– Әйдәгез,сөйләшеп алабыз ("Син кайдан?" темасына *диалог)*

– Рәхмәт, бик яхшы.Әйдәгез күңелле уен уйныйк. (Кроссворд чишү).

1. "Туган тел" шигырен кем язган? (Тукай )
2. Сез кайсы республикада кунакта? (Татарстан)
3. Татарстан флагының бер төсе? (кызыл)
4. 2013 елда Татарстанда нинди зур халыкара спорт ярышлары узды? (универсиада)
5. Татарстан дәүләт гимнын кем язган? ( Яхин)

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | т | у | к | а | й | | | | | |
| | | | | | | | т | а | т | а | р | с | т | а | н |
| | | | | | | к | ы | з | ы | л | | | | | |
| у | н | и | в | е | р | с | и | а | д | а | | | | | |
| | | | | | я | х | и | н | | | | | | | |

**3. Уку мәсьәләсен кую.**

– Укучылар, әйтегез әле, без кайсы шәһәргә килдек? *(Казанга) Слайд (Казан күренеше)*

– Димәк, бүген безнең темабыз нинди шәһәр турында? *(Казан)*

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү. (Казан турында шигырь)**

– Матур шигырьдән соң, кәефебез күтәрелде. Дәрес-сәяхәтебез дә шулай күңелле үтсен. Чыннан да, бүген без сезнең белән гүзәл шәһәребез, республикабызның башкаласы – Казан турында сөйләшүне дәвам итәбез. Әйдәгез әле укучылар, бергәләп Казан буйлап сәяхәткә чыгабыз. Миңа сезнең белән күңеллерәк булыр.Тукталышлар бит гади түгел. Сезнең анда белемнәрегез кирәк булачак. Истәлекле урыннарны искә төшерик әле. *Слайд (истәлекле урыннар)*

*Көтелгән җавап.* Кол Шәриф мәчете, Опера һәм балет театры, “Әкият” курчак театры, Кремль, Сөембикә манарасы, Казан загсы.

– Укучылар, шәһәребезнең исеме ни өчен Казан дип атала?

*Көтелгән җавап.*Балалар риваятьләр сөйли.

– Мин дә сезгә бер риваять сөйлим.(Казан турында риваять)

– Әйдәгез Меңъеллык паркта утырып ял итик (физминутка Җыр “Мин, син. без”) *Слайд (парк рәсеме )*

– Хәзер сөйләшеп алыйк. *Слайд (сөйләм ситуацияләре)*

– Укучылар, хәзер карточкалар белән эшлик. Карточкаларда җөмләләр язылган. Ике раслауның кайсысы дөрес? *(карточкалар белән эш)*

*Слайд( йолдыз рәсеме)*

**III.Рефлексия**

“Казан” тексты белән эш. *Слайд (Юнеско йолдызы)*

– Сез дә бүген йолдызлар кебек балкыдыгыз, минем бик яхшы дусларым, юлдашларым булдыгыз.

Бүгенге дәресебезнең истәлеге итеп, мин сезгә хисләр дәфтәрен бүләк итәм. Бәхетле мизгелләрне шушы дәфтәрләргә язып барырсыз.

**1. Өй эше.** Ә бүген мин сезгә өй эше итеп, шушы дәфтәрләргә Казан турында хисләрегезне, уйларыгызны язып килергә тәкъдим итәм.

– Конвертларыгызны алыгыз, анда рәсемнәр, Казанның үзегезгә охшаган истәлекле урынын дәфтәрләргә беркетергә кирәк, мин булышам.

**2. Бәяләү**. Алдыгызда биш канатлы йолдыз. Димәк, сез бүген барыгыз да бишле билгесе алдыгыз.

Йолдызлы сәгатьләрегез күп булсын.Казан шәһәренең киләчәге якты булсын. Сез дә киләчәктә йолдыз булырсыз. Казаныбыз күгендә балкырсыз.

Укытучы йолдыз турында шигырь сөйли *Слайд (Йолдызлар күренеше)*

## КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯНЕҢ БЕР ЭЛЕМЕНТЫ БУЛАРАК СӨЙЛӘМ КАЛЫПЛАРЫ

***Р.З. Гайсина,***
*ТР Бөгелмә муниципаль районы1нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Телгә өйрәтү үзе бер кызыклы, җаваплы, осталык сорый торган эшчәнлек. Без күп теллелек шартларында яши һәм яшәячәк буынга белем бирәбез. “Телләр белгән – илләр гизгән,” – ди татар халкы. Безнең укучыларыбыз да өйрәнгән телләрен аңлый, ул телдә аралаша, сөйләшә ала торган булырга тиешләр. Шуңа күрә дә, укыту эшчәнлегендә традицион тел өйрәтү ысуллары белән генә чикләнмичә, яңа технологияләрне өйрәнергә, алардан

файдаланырга кирәк. Шундый яңалыкларның берсе итеп, Н. В. Максимов тәкъдим иткән сөйләм калыпларын санаийм. Гомүмән алганда, дәреснең сыйфаты укытучының ничек әзерләнүеннән тора. Тел материалын мөмкин кадәр гадиләштереп, сөйләмгә өйрәтү, сөйләмнән тел материалына килү мөһим. Татар теленең килеш формаларын үзләштерү өчен укучыларның аларны ятлап, исемнәрне сөйләмнән аерып, килеш белән төрләндерүне үзмаксат итеп куюю уңышлы алым булып тормый дип саныйм. Юнәлеш килешен менә ничек аңлатам:

| | Кем? | Кая? | Нишли? | | -мы, -ме |
|---|---|---|---|---|---|
| Әйе, | мин | мәктәпкә | барам | бармыйм. | |
| Юк, | син | шәһәргә | барасың | бармыйсың. | |
| Әлбәттә, | ул | кунакка | бара | бармый. | |
| | без | театрга | барабыз | бармыйбыз. | |
| | сез | | барасыз | бармыйсыз. | |
| | алар | | баралар | бармыйлар. | |

Һәрбер багананы вертикаль юнәлештә тутырыбыз. Һәр баганадан соң нәтиҗә ясыйбыз. Икенче багананы тутырганнан соң, бу сүзләрнең нинди сорауга җавап бирүләре, нинди сүз төркеменә керүләре турында сөйләшәбез. (Кем? соравына җавап бирәләр, зат алмашлыклары булалар). Өченче багананы тутырганнан соң сорыйм: Что общего между этими словами? (Есть окончания -га, -гә, -ка, -кә; отвечают на вопрос **Кая?**) То есть слова с окончаниями -га, -гә, -ка, -кә отвечают на вопрос Кая? (Шулай ук нечкә, калын булуларын тикшерәбез). Дүртенче багананы тутырганнан соң: Обратите внимание на окончания, что они означают? -м к какому слову относится? (Мин). Фигыльләрнең заманнары билгеләнә. (Хәзерге заман хикәя фигыль).

– «Мин мәктәпкә барам», действие происходит? А если действие не происходит, как мы скажем?

– Мин мәктәпкә бармыйм.

– Окончания -мый, -ми образуют отрицательную форму глагола.

– Окончания вопросительного предложения -мы, -ме. (Син мәктәпкә барасыңмы?).

Таблица тезелеп беткәннән соң, диалог төзибез. Сөйләм моделен ятлап бетергәнче, шушы таблица өстендә эшлибез. Соңыннан монолог төзибез.

Хәзерге заманны өйрәнеп беткәч, билгеле уткән заманга, аннан соң билгесез үткән заманга күчәбез.

Без барыбыз да дәрестә сораулар бирәбез, ләкин безнең сорауларыбыз беръяклы гына. Укытучы сорау бирә, ә балалар җавап кайтара. Ә бит балалар үзләре дә сорау бирә белергә тиеш. Менә шушы сөйләм калыбына таянып, балалар җиңел генә сорауларны үзләре дә төзи алалар.Сорауга каршы сорау бирергә өйрәнәләр.

Башлангыч сыйныфларда гади таблицалар төзелә, ә югарырак сыйныфларда катлауландырыла. Шушы ысул белән кушма җөмлә төзергә өйрәтергә дә була. Шуннан соң монологка чыгабыз, текст төзибез. Ә текст төзи алгач, укучылар үзләре генә сочинение (инша) дә яза ала дигән сүз.

Тик бер хатадан сакланырга кирәк, сөйләм моделе буенча артык күп эшләү: берсен өйрәтеп бетермичә икенчесенә күчү, яисә бер дәрестә ике таблица өйрәнү. Бер сөйләм моделен өйрәтеп бетермичә, икенчесенә күчү; яисә бер дәрестә ике сөйләм моделен өйрәтү.

Мин дәресләремдә шушы сөйләм калыпларын кертәм һәм бу бик яхшы нәтиҗә бирә.Укучылар мондый дәресләрдә актив катнашалар. Җавапларын үз-үзләренә ышанып бирәләр.

Бу технология буенча елына 30 сөйләм моделе өйрәтеп була. Аларга нигезләнеп, дәреслектәге темаларны билгеле бер калыпны өйрәнүгә юнәлтергә, укучыны җиңел генә сөйләмгә алып кереп китергә мөмкин.

## РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ ИҖАДИ ҮСТЕРЕЛЕШЛЕ УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

***Сания Фатхлисламова,***
*Бөгелмә шәһәре 8нче урта*
*мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар телен чит тел буларак укытуда заманча технологияләрне куллану безнең эштә төп урынны алып торырга тиеш. Мин практикамда шәхескә юнәлтелгән технологияләрне куллланырга тырышам. Укучыларның үз хезмәтләрен үзанализ яки үзбәя аркылы бәяләргә тәкъдим итәм. Үзбәя кую схемалары белән укучылар инде күптән таныш, схемалар һәр укучының алдында ята. Укучы дәреснең һәр этабында үзенең эшчәнлеген бәяләргә тиеш була, ахырдан гомуми билге чыгарыла. Соңыннан укытучы укучылар белән берлектә эшне кабат тикшерә. Үзбәя куела.

Иҗади үстерелешле укыту технологиясе укучыга иҗади үсәргә ярдәм итә. Төрле темаларга сөйләшү оештырганда, укучыларны, белем дәрәҗәләренә карап, берничә төркемгә бүлеп утыртам. Укучылар алдына проблемалы сорау куела: “Син спорт белән дусмы?” Сөйләшүне төрлечә дәвам итәргә кирәк. Төркемдәге һәр укучы үз фикерен тулысынча, мисаллар белән сөйләп бирә һәм шулай ук үзбәя куела.

Татар телен чит тел буларак өйрәтү процессында уеннардан файдалану укучыны белем алырга дәртләндерә, аларда фән белән кызыксыну уята. Аеруча грамматик уеннар баланы фикерләргә,

эзләнергә өйрәтә, телләр белүнең тормышта кирәк булуына төшендерә. Уен барышында балалар берләшә, бер-берсенә ярдәм итә, аларда үз көчләренә ышаныч арта. Өйрәнелгән темалардан соң үткәрелгән уеннар аеруча нәтиҗәле була. Ул укучыларның сүз байлыгын арттыра, уен белән мавыккан укучы, курку хисен җиңә, сөйләм ситуациясенә җиңел килеп керә.

Рус телле балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятырлык уеннар бик күп. Мәсәлән:

1. Аерым билгеләр буенча сүзләр табу (беренче аваз, хәреф һәм иҗек буенча; бирелгән тема буенча; рәсем буенча; соңгы хәреф буенча; синонимнар, антонимнар табу).

2. Сүзләрне тергезү (төшеп калган хәрефләрне кую; таралган хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштыру; таралган сүзләрдән җөмләләр төзү; яңа сүз ясау өчен хәрефләр (иҗекләр) өстәү яки алып ташлау)

3. “Тирәбездә нәрсәләр бар?” уены (әйләнә – тирәдәге мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атау)

4. “Кем яхшы күрә?” (рәсемнәрдә сурәтләнгән әйберләрне, аларның билгеләрен, хәрәкәтләрен санау).

5. “Үзебезнең типография” (өйдә укылган хикәя буенча кечкенә китапчыклар ясау)

6. “Кәефең ничек?” (укучының кәефенә туры килүче смайликлы рәсемне сайлап сөйләве).

7. Предметларны чагыштыру һәм шуларны рәсемнәргә төшерү.

8. Сынамышлар, тизәйткечләр, җырлар, табышмаклар, башваткычлар, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллану да татарча сөйләшергә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия. Алар укучыларның белемен, осталыгын, иҗади эшчәнлеген үстерә.

Рольле уеннарга аерым тукталып китәсем килә. Аларны эш барышында актив кулланам, тәкъдим ителгән ситуацияне күзаллап, укучылар рольле уеннарда теләп катнаша. Аларны

парларда, төркемнәрдә үткәрергә мөмкин. Рольле уен катнашучылар һәм тыңлаучылар өчен бер дәрәҗәдә файдалы. Укучыларда төрле сөйләм формаларын кулланып сөйләшүдә катнашу, нидер сорау яки әңгәмәдәшенә җавап бирү ихтыяҗы туа. Рольле уен берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта аңа әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау. Уенны оештырганда, укытучы берничә алшартны истә тотарга тиеш:

1) укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру;
2) сөйләм эшчәнлегенең дәрәҗәсен истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү, укучыларның мөмкинлекләренә игътибар итү;
3) укучының кәефен тоемлап, уңай нәтиҗәгә ирешүгә омтылу;
4) укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне еш куллану;
5) үзара ярдәмләшү, телдән актив аралашу мохите булдыру.

Соңгы вакытта җәмгыятьтә барган үзгәрешләр белән беррәттән илебезнең мәгариф системасында укыту эчтәлеген яңарту процессы бара. Аның үзәгендә - шәхес, ягъни - укучы. Тирән белемле, югары әхлаклы, үз – үзен иҗади үстереп, шәхес буларак танытучы укучы тәрбияләү һәр укытучының бурычы.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү барышында файдалы, кызыклы итеп, заманча технологияләрдән файдаланып, югары нәтиҗәләргә ирешергә тырышам. Дәресләрдә балаларның танып белү эшчәнлеген үстерү өчен эш төрләрен дифференцияләштерү дә зур нәтиҗә бирә. Ягъни, сыйныфтагы һәр балага шәхси якын килеп, шәхси үзенчәлекләрен истә тотып, бирем һәм күнекмәләрне аерып бирү. Бу бигрәк тә йомшак укучылар өчен мөһим. Максатым: аларның белемнәрен, укуга карата кызыксынуларын һәм омтылышларын үстерү. Белемнәре, интеллектуаль дәрәҗәләре югары булган укучылар катлаулы,

иҗади характердагы биремнәрне эшли алалар. Мәсәлән: дәрес барышында 7–8 таныш һәм таныш булмаган сүзләр әйтеп чыгам. Укучылар хәтерләрендә калдырганнарын дәфтәрләренә язалар, үзбәя куялар. Көчле укучылар шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр, йомшаклары сүзтезмәләр уйлыйлар. Кул астында төрле дәрәҗәдәге дифференциаль карточкалар, схемалар, рәсемнәр тотам. Газета-журналлар да бу вакытта ярдәмгә килә. Дифференциаль өй эше бирү дә гадәткә керде. Аны мин дәреснең беренче яртысында, укучы әле арып өлгермәгәндә бирергә тырышам:

а) дәрестә укылган тексттагы исемнәрнең килешләрен билгеләргә;

б) сыйфатларны табарга;

в) фигыльләрнең заманнарын билгеләргә;

Иҗади характердагы эшләр башкарганда да дифференциаль якын килеп эшләп була. Изложение язганда сыйныф ике төркемгә бүленә. Бер төркемгә текст танышу өчен өйгә бирелгән була. Көчле укучылар инде эшкә керешкәндә, йомшак укучылар, бер түгәрәккә җыелып, укытучы ярдәме белән язарга әзерләнәләр (сорауларга җавап бирәләр, план төзиләр).

Яңа технологияләр татар телен өйрәнүче укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлеккә өйрәтә. Компьютер технологияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерергә, информацион технологияләр дөньясындагы яңалыклар белән кызыксынырга теләк уята. Бүгенге көндә татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту зур тырышлык сорый. Компьютер технологияләрен кулланып укыту шушы проблеманы хәл итәргә булыша. Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшләргә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар әзерләргә өйрәтә.Укучылар аерым темаларга презентацияләр төзеп чыгышлар ясыйлар. Төрле конкурсларда катнашалар. Сөйләм үстерү дәресләрендә бу презентацияләрне куллану да бик

файдалы. Әзер материаллар рус телле балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уята. Мисал өчен “Минем гаиләм” темасын гына алыйк. Гаилә әгъзаларының әйтелеше татар телендә яңгырап, укучыларда сүзләрне дөрес әйтүгә һәм дөрес язуга булышлык итә. Үрнәк диалоглар тыңлау, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерә.

Укучыларның төрле әзерлек, белем дәрәҗәләренә юнәлдерелгән стандарт булмаган эш алымнарының иң отышлысы – проект эшен оештыру. Әлеге эш төре укучыларны актив эзләнү - тикшеренү эшчәнлегенә тартырга ярдәм итә. Укучылар башлангыч сыйныфлардан ук фәнни-тикшеренү өлкәсендә беренче тәҗрибә туплыйлар, тикшерү методлары белән танышалар. Тикшерү нәтиҗәләре буенча презентацияләр әзерлиләр, аны яклап чыгыш ясыйлар. Проектлы укытуның мавыктыргыч, уен формасында булуы һәр дәресне укучылар өчен бәйрәмгә әйләндерә. Укучылар яңадан – яңа уңышларга ирешергә тырыша. Әлеге эшчәнлек татар телен кызыксынып өйрәнергә, грамоталы язарга өйрәтә.

Татар теле укытучыларының төп максатлары:

- укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- логик фикерләү сәләтен, сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;
- татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән даими таныштырып тору.

Бу максатларга ирешү өчен, рус балаларына татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Укучыларның танып белү активлыгын арттыру;
- Иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- Тыңлап аңлау (аудирование), сөйләү, уку, язу күнекмәләрен формалаштыру.

Бүгенге мәктәп укытуның традицион формалары белән генә чикләнеп калмый. Аның эчтәлеге инновацион процесслар белән тулыландырылганда гына алга китешне, үсешне күрергә мөмкин. Һәрбер сыйныфта дәреслек белән генә чикләнмичә, методик

кулланмалар, дидактик материаллар, җыентыклар, таблицалар, сүзлекләр, компьютер, проектор, интерактив такта, интернет челтәре кебек чаралардан да актив файдаланырга кирәк. Рус телендә сөйләшүче балаларга дәүләт телен үзләштерү өчен шартлар тудырылган. Хезмәтебезгә иҗади якын килеп, заманча технологияләрне урынлы кулланып эшлисе генә кала.

## ИШЕТЕП АҢЛАУ АҢЛАУҺӘМ ҖАНЛЫ СӨЙЛӘМДӘ КАТНАШУ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ
**(рус төркемендәге укучылар өчен)**

***А. М. Шәрифуллина,***
*ТР Бөгелмә муниципаль районы*
*аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче*
*5нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:**

- чит кеше сөйләгәнне яки укыганны тыңлап аңларга өйрәтү материалы белән таныштыру;
- фикерне әйтеп бирергә һәм башкаларның сөйләмен аңларга өйрәтү;
- ишетеп аңлау күнегүләрен кулланып, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, татар теленә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:**видеоязма, аудиоязма, карточкалар

**Дәреснең барышы**

Рус телле укучыларны татар теленә өйрәткәндә, беренче чиратта, чит кеше сөйләмен тыңлап аңларга өйрәтү эше тора. Бу күнегүләр системасы “аудирование” күнегүләре дип атала.

Аудирование күнегүләренең төп максаты:

- ишеткәнне аңларга өйрәтү;
- үз фикереңне әйтеп бирергә, башкалар сөйләгәнне аңларга өйрәтү;
- укучыларны татар халкының мәзәкләрен, табышмакларын, әйтемнәрен ишетеп аңларга өйрәтү;
- ишетеп аңлау күнегүләре кулланып, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру, аңа карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Дәреслектә ситуатив биремнәр бик күп, ләкин аудирование күнегүләре юк дәрәҗәсендә. Рус телле укучылар өчен бердәм республика тестының беренче бүлеге укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Моңа әзерлек эше башлангыч сыйныфларда ук башлана. Укучыларны чит кеше сөйләмен тыңлап аңларга өйрәтү максатыннан дәреснең төрле этапларында аудирование күнегүләре кулланыла

**1нче күнегү:** “Һава торышы”.




Укучылыр төркемләп утыра. Аларга Татарстан картасы таратыла. Аудиоязма тыңлаганда укучылар Татарстан шәһәрләрендә һава торышы ничек икәнен билгелиләр. *Максат*: шәһәр исемнәрен искә алу, саннарны кабатлау, текстны аңлау дәрәҗәсен билгеләү. *(язма ике мәртәбә тыңлатыла)*

*Бүген 10 нчы август, пәнҗешәмбе. Татарстанда ике ай хөкем иткән коры, эссе һава, ниһаять,төшә башлады. Хәзер республикабызда җылы, сәламәтлек өчен уңай һава торышы күзәтелә.*

*Казанда +29 – +30градус җылы булачак, төнлә һава температурасы +15 – +17 градуска кадәр төшәчәк.*

*Республикабызның төньяк-көнчыгыш районнарында – Яр Чаллыда, Алабугада һава торышы сизелерлек бозыла һәм температура +20 – +22 градуска кадәр җылы булачак. Вакыты белән явым-төшем көтелә.*

*Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында –Әлмәттә, Бөгелмәдә җылы, явымсыз, җылылык +25 – +29 градус.*

*Төньяк-көнбатыш районнарында – Яшел Үзәндә алмашучан болытлы һава, урыны белән яңгырлар көтелә. Җылылык +23 – +26 градус.*

*Татарстан республикасының көньяк-көнбатыш районнарында – Буада, Тәтештә һава торышы тотрыклы. Явым-төшем көтелми. Җылылык +27 – +29 градус. Бу хакта Татарстан Республикасының гидрометеорология идарәсе хәбәр итә.*

– Татарстандагы кайсы шәһәрләр искә алына? *(Казан, Яр Чаллы, Алабуга, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Тәтеш, Яшел Үзән)*

– Казанда һава торышы нинди?

– Яр Чаллы, Алабуга кайда урнашкан? Алардагы һава торышы турында сөйләгез.

– Көньяк-көнчыгышта кайсы шәһәрләр урнашкан? Аларда һава торышы нинди?

– Яшел Үзән Татарстанның кайсы ягында урнашкан? Һава торышы турында сөйләгез.

– Көньяк-көнбатыш районнарында һава торышы нинди?

**2нче күнегү**

**Ял итү минутлары**н да файдалы итеп үткәрергә мөмкин. Өлкән классларда җыр тыңлаганда, түбәндәге биремне бирергә мөмкин:



– Без ял итеп алабыз. “Мин яратам сине, Татарстан” җырын тыңларбыз. Сүзләрен белүчеләр кушылып җырлый ала. Шул вакытта һәр төркем җыр текстында булган тартым кушымчасы булган исемнәрне табарга тиеш. Кемнәр күбрәк таба, шулар җиңә.

«Мин яратам сине, Татарстан!»
(Р.Андреев көе, Р.Рәкыйпов сүзләре)

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам,
Күк күкерәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,
Горур халкың өчен яратам,
Җан эреткән әнкәм телең өчен –
Татар телең өчен яратам.
Мин яратам сине, Татарстан,
Тугайларың өчен яратам,
Тукайларың, Сәйдәшләрең өчен,
Җәлилләрең өчен яратам.

**Нәтиҗә:** *җиңүчене билгеләү*

**3нче күнегү**

**Послушайте текст.** Перед вами лежат листы с заданиями. Вы должны правильно выбрать слово, которое соответствует содержанию текста




*Без туган шәһәр – Бөгелмә. Ул Татарстан Республикасының*

*көньяк-көнчыгышында. Бөгелмә яклары киң кырларга, шаулы урманнарга, көмештәй ялтырап агучы елгаларга бай.*

*Бөгелмә борынгы, бай тарихлы шәһәр. Шәһәребез көннән-көн матурая, үсә. Яңадан-яңа йортлар төзелә, төрле спорткомплекслар калкып чыга, балалар бакчалары, кибетләр үз ишекләрен ача.*

*Бөгелмә шәһәре үзенең данлыклы кешеләре, галимнәре, язучылары белән дә дан тота. Яраткан җырчыларыбыз Алсу, Надежда Кадышеваны кем генә белми икән?!*

*Шәһәрдә күп кенә уку йортлары, музейлар, парклар, театр бар. Әлеге гүзәл шәһәрдә күп кенә милләт вәкилләре үзара бик тату, дус яшиләр.*

*Бөгелмә ул – дуслык шәһәре. Бөгелмә – тарихи шәһәр. Бөгелмә – киләчәккә ныклы адым белән алга баручы шәһәр.*

1. Бөгелмә Татарстан Республикасының....
   1) көньяк-көнбатышында
   2) көньяк-көнчыгышында
   3) төньяк-көнчыгышында
2. Бөгелмә ... шәһәр.
   1) тарихи
   2) зур
   3) яшь
3. Шәһәребез ... .
   1) искерә
   2) пычрана
   3) матурая
4. Бөгелмә шәһәре ... дан тота.
   1) галимнәре белән
   2) эшчеләре белән
   3) укучылары белән
5. Шәһәрдә милләт вәкилләре ... яшиләр.
   1) начар

2) яхшы

3) тату

**Нәтиҗә:** *Без туган шәһәрнең исеме ничек? Ул нинди?(монолог)*

**4нче күнегү**




Балалар мультфильм карарга ярата. Татар телендә чыккан мульфильмнар да хәзер бик күп. Мультфильмнан өзек алып, балалардан эчтәлеген сөйләтергә яки өзеккә исем бирдерергә мөмкин.

– Укучылар, сез мультфильм карарга яратасызмы? Татар мультфильмнарын караганыгыз бармы?

Сезгә хәзер 4 мультфильм тәкъдим ителә, аларга исем табарга кирәк. *(укучыларга, сайлап алу өчен, карточкалар тәкъдим ителә)*

– Мультфильм геройлары кебек сез дә “Китапханәдә” дигән темага диалог төзегез.

– Кайсы төркемнең диалогы яхшырак булыр икән?

**5 нче күнегү**

Аудиоязма буенча таблица тутыру.




– Әдәбият дәресендә Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында өйрәндек. Хәзер Г.Тукай турындагы белемнәрне тикшереп карыйк. *(җөмләләр укыла – дөресме, дөрес түгелме икәнлеген билгеләргә кирәк)*

**Нәтиҗә:** *Габдулла Тукай турында* ***беләсез*** *дип әйтергә мөмкин.*

Шулай итеп, ишетеп аңлау күнегүләрен төрлечә үткәрергә мөмкин. Әлбәттә, бөтен дәрес аудирование белән узарга тиеш түгел. Ул бары тик дәреснең билгеле бер өлешендә генә булырга мөмкин.

## КЫШКЫ УЕННАР
## (коммуникатив технологиягә нигезләнеп төзелгән дәрес эшкәртмәсе)

***А. Р. Хаева,***
*ТР Бөгелмә муниципаль районы*
*аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче*
*6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:**

1. Өйрәнелгән сүзләрне аралашуда кулланырга күнектерү.
2. Сөйләм телен үстерү.
3. Дуслык хисе тәрбияләү.Татар телен өйрәнүгә карата кызыксыну уяту.

**Дәрес тибы**: лексик-грамматик күнекмәләрен камилләштерү (ЛГКК)

**Уку эшчәнлеген оештыру**: парлап, төркемнәрдә, фронталь, үзлектән эшләү.

**Уку эшчәнлеген төрләре:** әңгәмә, рәсем буенча сөйләү, күнегүләр эшләү, өлешчә эзләнү, диалогик һәм монологик сөйләм.

**Дәреслек:** Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ә. Гыйниятуллина. Күңелле татар теле (3 нче сыйныф). – Казан: Татармультфильм нәшрияты, 2013.

**Җиһазлау**: рәсемнәр, диск, интерактив такта, индивидуаль карточкалар, иҗади биремнәр, күрсәтмә материаллар.

**I. Оештыру өлеше**

-Хәерле көн! Хәерле көн!

-Хәлләрегез ничек? Яхшы.

-Ә сезнең хәлләрегез ничек? Яхшы. Рәхмәт!

-Утырыгыз.

**II.Актуальләштерү өлеше**

–Дәресне авазларның дөрес әйтелешеннән башлыйбыз.

**к**

**о**

**в**

**[к] [к]**

**[о] [ŏ]**

**[в] [w]**

кем такта

вагон кош

ваза авыл

– Балалар, тәрәзәгә карагыз. Әйтегез, хәзер иртәме, көндезме, кичме? (Хәзер көндез).

– Күктә кояш бармы? (юк, әйе...)

– Кояш нинди төстә була? (Кызыл,сап-сары, алсу, караңгы).

– Әйдәгез, җырлыйбыз **(диск).**

– Әйдәгез.

Иртә белән кояш алсу,

Көндез ул сап-сары.

Кич белән кояш кызыл,

Ә төнлә караңгы

3) –Әйдәгез, уйныйбыз!

- Уенның исеме **«Сораулар һәм җаваплар»**

- Синең исемең ничек? (Минем исемем...).
- Син ничәнче сыйныфта укыйсың? (Мин өченче сыйныфта укыйм).
- Син кайда яшисең? (Мин Бөгелмәдә яшим).
- Хәзер кайсы вакыт? (Хәзер кыш).
- Бүген урамда салкынмы, җылымы? (Бүген урамда салкын).
- Син чаңгыда шуарга яратасыңмы? (Әйе, мин чаңгыда шуарга яратам).
- Таня Денистан сора:
- Какой сегодня день? (Бүген көн нинди?)
- Есть ли на улице ветер? (Урамда җил бармы?)
- На улице снег идет? (Урамда кар явамы?)
- Ты на санках кататься любишь? (Син чанада шуарга яратасыңмы?)

**III. Уку мәсьәләсен (сорау, максат, проблема) кую.**

**1**.-Балалар, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшкәнне, үзегез әйтерсез. Шуның өчен әйдәгез кроссворд чишәбез. Рәсем урынына сүзләрне татарча әйтегез **(интерактив такта).**

| | |
|---|---|
| **К**АР | Ш**У**ГАЛАК |
| К**Ы**Ш | ТИМ**Е**РАЯК |
| ЧЫР**Ш**Ы | ЧА**Н**А |
| ХОК**К**ЕЙ | КУЯ**Н** |
| УЕНЧ**Ы**К | Ч**А**ҢГЫ |
| БҮ**Р**Е | |

– Нинди тема килеп чыкты? (Кышкы уеннар).

– Дөрес, «Кышкы уеннар» турында сөйләшербез. Ә дәресебездә без нәрсәләр эшләрбез соң, максатыбыз нинди булыр

**Дәрестә без:**

1) Яңа сүзләр белән танышырбыз;
2) текстны укырбыз, сорауларга җавап бирербез;

3) хикәя һәм диалоглар төзербез.

– Балалар, әйтегез әле, сез нинди кышкы уеннар беләсез? (Тимераякта шуу; чанада шуу; чаңгыда шуу; хоккей уйнау; кар бабай ясау.)

**2. Яңа сүзләр белән таныштыру**

– Ә хәзер яңа сүзләр белән танышабыз. Тактага карагыз. Мин укыйм, ә сез игътибар белән тыңлагыз.

**Һәрвакыт – всегда, аннан соң – потом, тау – гора, озак – долго**

Ә хәзер тикшереп карыйк, сез ничек сүзләрне истә калдырдыгыз. Карагыз әле, укучылар, бүген безнең дәрестә алмагач та кунакта. Алмагачка булышырга кирәк: алмалар җыярга. Һәр алмада сүз язылган, аларны тәрҗемә итәргә кирәк. -Менә алмагачка да булыштык, бик яхшы.

**IV. Физминутка**

– Әйдәгез, ял итәбез.(Әйдәгез).

– Басыгыз. («Кәрия-Зәкәрия» җыры)

**V. Уку мәсьәләсен чишү**

**1) Текст өстендә эш**

**а)** – Эшне дәвам итәбез. Балалар, карточкаларда текстны табыгыз. Хәзер мин укыйм, ә сез игътибар белән тыңлагыз һәм сорауга җавап бирегез:

– Текст нәрсә турында?

**Кышкы уеннар**

Дима, Азат, Әмир – дуслар. Алар һәрвакыт бергә уйныйлар.

Бүген көн җылы, җил юк, кар ява. Дима чана ала, Азат белән Әмир чаңгы алалар. Малайлар бик озак шугалакта шуалар. Аннан соң бергә дәрес әзерлиләр.

– Текст нәрсә турында? (Кышкы уеннар турында).

**ә)** -Хәзер интерактив тактага карагыз. Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз**. (**1. Бүген көн җылы. 2.

Малайлар бик озак шугалакта шуалар. 3. Дима, Азат, Әмир – дуслар. 4. Дима чана ала, Азат белән Әмир чаңгы алалар.

**б)** –Ә хәзер текст буенча сорауларга җавап бирегез. Икенче конвертны алыгыз. Кемгәдер сораулар, кемгәдер җаваплар эләкте. Сорауга дөрес җавапны табарга кирәк.

**Сораулар:**

1. Дима, Азат, Руслан кемнәр? (Дима, Азат, Әмир – дуслар).

2. Алар һәрвакыт бергә уйныйлармы? ( Әйе, алар һәрвакыт бергә уйныйлар).

3. Көн нинди? ( Көн җылы).

4. Урамда кар явамы? (Әйе, урамда кар ява).

5. Урамда җил бармы? (Юк, урамда җил юк).

6. Дима нәрсә ала? (Дима чана ала).

7. Ә Азат белән Әмир нәрсә алалар? ( Ә Азат белән Әмир чаңгы алалар).

8. Малайлар кайда шуалар? (Малайлар тауда шуалар).

9. Малайлар тауда ничек шуалар? ( Малайлар тауда озак шуалар).

10. Аннан соң алар бергә нәрсә әзерлиләр? (Аннан соң бергә дәрес әзерлиләр).

**2)**–Әйдәгез, уйныйбыз! **(«Түбәтәй» уены)**

**VI. Эшли белү күнекмәләрне формалаштыру**

– Балалар, менә без яңа сүзләр белән таныштык. Текст өстендә эшләдек, сорауларга җавап бирдек. Ә хәзер без төркемнәргә бүленәбез.

1) Беренче рәт өченче конвертыгызны ачыгыз. Бирем шундый:

– Сезгә җөмләләрне дөрес тәрҗемә итәргә кирәк.

Я всегда делаю уроки. Саша долго на улице играет. Дети на горе катаются. (Мин һәрвакыт дәресләр әзерлим. Саша урамда озак уйный. Балалар тауда шуалар).

2) Икенче рәт – диалогларга төшеп калган репликаларны өстәргә кирәк.

а) – Бүген көн нинди?

– ..... .

– Ничә градус салкын?

– ..... .

ә) – Коля, син шугалакка барасыңмы?

– ..... .

– Сәгать ничәдә барабыз?

– ..... .

3) Өченче рәт – төркемнәргә бүленегез (4 кеше).

– Сез «Кышкы уеннар» темасына 5-6 җөмлә төзегез.

**VII. Рефлексив кабатлау. Үзбәя.**

- Укучылар, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Нәрсәләр белдек? (Кышкы уеннар турында. Азат белән Руслан яхшы дуслар. Алар бергә уйныйлар да, дәрес тә әзерлиләр).

- Нинди яңа сүзләр белән таныштык? (Һәрвакыт – всегда, аннан соң – потом, тау – гора, озак – долго).

– Сезнең өчен нәрсә авыр булды?

– Нәрсә ошады?

– Кыш көне нинди уеннар уйнарга була? (Тимераякта, чанада, чаңгыда шуарга, хоккей уйнарга, кар бабай ясарга).

(билгеләр кую)

**VIII. Өй эше**

Яңа сүзләрне кабатларга һәм «Кышкы уеннар» темасына 5 җөмлә төзергә.

Саубуллашу.

## ЭЧТӘЛЕК

**Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф**. Татар теленә өйрәтүдә кулланылган педагогик технологияләр............................3

**Әбсәләмова И., Әхмәтова Г.** «Чишмә» темасына бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе. Технологик карта..................13

**Исмәгыйлова Л.** Казан – республикабыз башкаласы..................29

**Гайсина Р. З.** Коммуникатив технологиянең бер элементы буларак сөйләм калыплары ...........................................................36

**Фәтхлисламова С.** Рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә иҗади үстерелешле укыту технологиясе........................................41

**Шәрифуллина А. М.** Ишетеп аңлау һәм җанлы сөйләмдә катнашу күнекмәләрен формалаштыру..........................................47

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән**


Корректура, компьютерная верстка, техническое редактирование
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.

Форм.бум. 60x84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 3,75.

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
www.irort.ru, irort2011@gmail.com